**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 20.07.2022** **№ 720**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 14 мартындагы 662 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмә»гә (Башкарма комитетның 16.09.2016 №1795, 29.04.2020 №37 карарлары редакциясендә), 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат эшкә кергәндә тапшыра:

а) Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керешү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элекке эш урынындагы яисә сайланулы вазыйфаны биләү урынындагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, милек хокукында аңа караган мөлкәт турында һәм муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керешү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына торышы буенча үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керешү өчен документлар тапшырган елга кадәрге календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне,

пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алынган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керешү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлары) цифрлы финанс активлары, хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) цифрлы валюта сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми күләме әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса һәм алар исәбеннән алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында.»;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» мәгълүмат сайтында https://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының эшләр идарәчесе Г.Ф. Сабировага йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов